РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» 06 2019 ел №448

Гражданнар табышының һәм 2019 елга
салым салынырга тиеш булган мөлкәтнең
чик күләмен билгеләү турында

Татарстан Республикасының 2007 елның 13 июлендәге «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль найм шартнамәләре буенча гражданнарга торак бирүгә аларның хокукларын гамәлгә ашыру турында» 31-ТРЗ номерлы Законы, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары өчен гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм торак урыннарына мохтаҗ дип танылган аз керемле гражданнарны исәпкә алу һәм аларга муниципаль торак фондыннан социаль найм шартнамәләре буенча торак бирү тәртибен билгеләү буенча методик рекомендацияләр нигезендә, шулай ук Торак кодексының 49, 51 статьяларына таянып, Башкарма комитет КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 11 апрелендәге «2018 елга салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең һәм гражданнарның кеременең чик күләмнәрен билгеләү турында " 228/1 номерлы Карарын гамәлдән чыгарырга.

2.Югарыда күрсәтелгән законны гамәлгә ашыру максатларында, 2019 елга Ютазы муниципаль районы буенча 1 м2 гомуми мәйданның уртача базар бәясен 26 402,42 сум күләмендә расларга.

3. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2019 елга

салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен билгеләү методикасын (Кушымта №1)

4. Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2019 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик кыйммәтен расларга (Кушымта №2).

5.Торак сәясәте бүлегенә гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда, № 2 кушымтада күрсәтелгән чик күрсәткечләрне кулланырга .

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Ютазы муниципаль районы

Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Н.А. Абильтарова

2-76-81

Кушымта №1

ТР Ютазы муниципаль районы

Башкарма комитеты карарына

“___” _________ 2019 ел

№448

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2019 елга салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең иң чик күләмнәрен билгеләү методикасы**

1. Муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак бирү нормасы буенча торак алуга базар хакының исәпләнгән күрсәткече яисә милек бәясенең чик күрсәткече (алга таба - исәп-хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП * РС * РЦ, биредә:

СЖ - базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече яки милек бәясенең чик күләме;

НП - гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - ТР Ютазы районы буенча торак бина мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе (2019 елга - 26402,42 сум).

Шулай итеп,

| Гаилә әгъзалары саны | Бер гаилә әгъзасына торак бирү нормасы | Гомуми мәйдан | 1кв.метрның уртача исәп-хисап базар бәясе | Базар бәясе исәп-хисап күрсәткече |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 33 | 33 | 26402,42 | 871 279,86 |
| 2 | 21 | 42 | 26402,42 | 1 108 901,64 |
| 3 | 18 | 54 | 26402,42 | 1 425 730,68 |
| 4 | 18 | 72 | 26402,42 | 1 900 974,24 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5 | 18 | 90 | 26402,42 | 2 376 217,8 |
| 6 | 18 | 108 | 26402,42 | 2 851 461,36 |
| 7 | 18 | 126 | 26402,42 | 3 326 704,92 |
| 8 | 18 | 144 | 26402,42 | 3 801 948,48 |
| 9 | 18 | 162 | 26402,42 | 4 277 192,04 |
| 10 | 18 | 180 | 26402,42 | 4 752 435,6 |

2. Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик әһәмиятенең күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$ПД = \frac{0{,}7*СЖ*ПС/(1-(1+ПС)^{-КП}}{0{,}3*РС},$$ биредә:

ПД - гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең исәп-хисап бәясе буенча торак урыны алу өчен иң чик күрсәткече - СЖ;

СЖ - социаль найм шартнамәсе буенча торак бирү нормасы буенча торак алуга базар хакының исәпләнгән күрсәткече;

ПС - бер айга кредит буенча процент ставкасы (унарлы вакланма)

ПС =елга 11,5%, ПС=11,5/100/12 = айга 0,0095833

КП - кредит бөтен срогы буенча кредит өчен түләүләрнең гомуми саны (айлар саны); КП=15 ел=180 ай.

РС-гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,3 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кереме белән нисбәте.

| Гаилә әгъзалары саны (РС) | Торак бирү нормасы буенча базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече (СЖ) | Айга кредит буенча процент ставкасы (уртача елллык - 11,5 %) (унарлы вакланма) | Кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте | 0,3*РС | Һәр гаилә әгъзасына туры килгән уртача айлык тулаем табышның чик әһәмияте |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 871279,86 | 0,009583333 | 0,7 | 0,3 | 19482,2 |
| 2 | 1108901,64 | 0,009583333 | 0,7 | 0,6 | 12397,8 |
| 3 | 1425730,68 | 0,009583333 | 0,7 | 0,9 | 10626,9 |
| 4 | 1900974,24 | 0,009583333 | 0,7 | 1,2 | 10626,9 |
| 5 | 2376217,8 | 0,009583333 | 0,7 | 1,5 | 10626,9 |
| 6 | 2851461,36 | 0,009583333 | 0,7 | 1,8 | 10626,9 |
| 7 | 3326704,92 | 0,009583333 | 0,7 | 2,1 | 10626,9 |
| 8 | 3801948,48 | 0,009583333 | 0,7 | 2,4 | 10626,9 |
| 9 | 4277192,04 | 0,009583333 | 0,7 | 2,7 | 10626,9 |
| 10 | 4752435,6 | 0,009583333 | 0,7 | 3 | 10626,9 |

Кушымта №2

ТР Ютазы муниципаль районы

Башкарма комитеты карарына

“___” ______ 2019 ел

№_______

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2019 елга салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең чик күләмнәре**

| Гаилә әгъзалары саны | Гаилә әгъзаларының яки ялгыз яшәүче гражданның милкендә булган һәм салым салынырга тиешле милекнең чик бәясе | Һәр гаилә әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килгән айлык тулаем табыш күләме |
|---|---|---|
| 1 | 871279,86 | 19482,2 |
| 2 | 1108901,64 | 12397,8 |
| 3 | 1425730,68 | 10626,9 |
| 4 | 1900974,24 | 10626,9 |
| 5 | 2376217,8 | 10626,9 |
| 6 | 2851461,36 | 10626,9 |
| 7 | 3326704,92 | 10626,9 |
| 8 | 3801948,48 | 10626,9 |
| 9 | 4277192,04 | 10626,9 |
| 10 | 4752435,6 | 10626,9 |